ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территориясендә урнашкан «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1; 2012, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш) 1 статьясындагы 1 өлешенең дүртенче абзацына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«13,5 процент (2017 – 2020 елларда 12,5 процент) – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап ун календарь ел үткәннән соң.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 22 февраль
№ 6-ТРЗ